**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«28» июль 2016 ел № 7/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
«Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенчахалык тыңлаулары нәтиҗәләрен карап, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Уставының 78, 79, 80 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз көченә керә, әгәр федераль законда башкача каралмаган булса.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
4. Калмия авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе, авыл хуҗалыгы һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Н.Р. Гыйлфанов